СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 2 » февраль 2021 ел** **№ 47**

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау хакында**

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, төгәлсезлекләрне бетерү һәм аны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына һәм норматив хокукый актларга туры китерү максатыннан, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Россия Федерациясе Президентының “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау турында” 01.03.2017 ел, № 96 Указы, Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 01.02.2005 ел, № 112 Указы нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервы турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркемнәре Исемлеге әлеге карарга кушымта итеп бирелгән форма нигезендә (2 нче кушымта) Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы тарафыннан төзелә һәм алып барыла һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана дип билгеләргә.

3. Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмә нигезендә кадрлар резервын формалаштыру эшчәнлеген оештыруны тәэмин итәргә.

4. Арча район Советының 2014 елның 05 апрелендәге «Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларына кадрлар резервы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясен йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
02.02.2021 ел, № 47
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервы турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәдә җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны оператив биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм куллану тәртибе һәм шартлары билгеләнә, моңа «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә контракт буенча билгеләнә торган башкарма комитетлар җитәкчеләре вазыйфалары керми.

1.2. Кадрлар резервы әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән вакантлы вазыйфаларны биләү өчен билгеләнгән тәртиптә формалаштырылган һәм әлеге вазыйфаларны биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган һәм һөнәри, эшлекле һәм шәхси сыйфатларга ия гражданнар төркемнәре исемлегеннән гыйбарәт.

1.3. Әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервында Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук Россия Федерациясе халыкара шартнамәләрендә катнашучы, алар нигезендә муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, алар кадрлар резервына кертүгә тиешле конкурс сайлавын уңышлы үткән чит ил гражданнары тора.

1.4. Кадрлар резервын формалаштыру түбәндәге максатларда башкарыла:

1) муниципаль хезмәткәрләр составының сыйфатын яхшырту, аларның һөнәри осталыгын күтәрүне стимуллаштыру;

2) муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны тиз биләү мөмкинлеген тәэмин итү;

3) кадрлар сайлау буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү;

4) гражданнарның муниципаль хезмәткә керүгә мотивациясен арттыру;

5) вазыйфага керешкәндә гражданнарның адаптация чорын кыскарту.

1.5. Кадрлар резервын формалаштыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

– Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын һәм тиешле муниципаль норматив хокукый актларны үтәү;

– кадрлар резервына керткәндә һәм анда булган гражданнар өчен кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын, һөнәри эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләүдә объективлык;

– кадрлар резервына керткәндә ихтыярыйлык булу;

– сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә гражданнарның кадрлар резервына керүнең тигез мөмкинлекләре;

– муниципаль хезмәт вазыйфасына кандидат квалификациясенең законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүе;

– кадрлар резервын формалаштыру һәм кадрлар резервына кертелгән гражданнар белән эшләү буенча конкурс чараларын уздырганда мәгълүматның хәбәрдарлыгы һәм ачыклыгы;

– җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең кадрлар резервы белән эшләгән өчен җаваплылыгы.

1.6. Кадрлар резервында тору вакыты 3 ел.

1.7. Гражданнар кадрлар резервына бер үк вакытта берничә вазыйфаны биләү өчен кертелә ала, шул исәптән берничә органга да.

1.8. Кадрлар резервына керү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу, кадрлар резервын формалаштыру һәм нәтиҗәле файдалану буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү максатыннан, Арча муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

1.9. Комиссия һәм аның шәхси составы турындагы нигезләмә Арча район Советы карары белән раслана.

1.10. Кадрлар резервын формалаштыру, Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү, вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркемнәре исемлеген булдыру һәм алып бару, Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган һәм исемлекне Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты кадрлар секторына йөкләнә.

## II. Кадрлар резервын формалаштыру

2.1. Кадрлар резервы гражданнарны Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркеменә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркемнәре Исемлегенә кертү юлы белән төзелә:

1) кадрлар резервына кертү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча;

2) муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе тарафыннан һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертү турында карар кабул итү.

2.2. Гражданнарны муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркемнәре Исемлегенә кертү Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган һәр вазыйфа буенча гамәлгә ашырыла.

2.3. Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты һәм

Комиссия тиешле килешүләр нигезендә җирлекләрдә һәм Арча муниципаль районы составына керүче башка җирле үзидарә органнарында кадрлар резервын формалаштыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.4. Конкурста сайлап алу Арча муниципаль районы башлыгы карары буенча түбәндәге нигездә үткәрелә:

1) җирле үзидарә органнарының вакантлы вазыйфаларны биләү өчен дәгъва кылучыларга ихтыяҗын ел саен бәяләү комиссиясе тәэмин итә. Кадрлар резервына ихтыяҗны бәяләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

– җирле үзидарә органының кадрлар белән тәэмин ителеше яисә әлеге оешмалар җитәкчесе вазыйфасын биләү өчен муниципаль учреждениенең кадрлар резервына ихтыяҗы;

– җирле үзидарә органының кадрлар резервы белән тәэмин ителеше;

– җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары барлыкка килү ихтималы, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына вакансия барлыкка килү ихтималы;

– органның кадрлар резервыннан чыгарылу фаразы.

2) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Арча муниципаль районы составына керүче җирлекләр тәкъдимнәре.

2.5. Кадрлар резервына керүгә конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелү турында мәгълүмат Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы сайтында остәмә рәвештә, конкурс нигезендә сайлап алу көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

– биләү өчен кадрлар резервы төзелә торган вазыйфаның исеме;

– муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәре вазыйфаларына куела торган кадрлар резервына керүгә дәгъва кылучыга карата таләпләр;

– тапшырылырга тиешле документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты;

– күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок;

– конкурсны уздыру датасы, урыны һәм тәртибе;

– конкурс турында төгәл мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, орган сайтының электрон адресы);

– башка мәгълүмати материаллар.

2.6. Муниципаль хезмәткә кадрлар резервына керү конкурсында катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы түбәндәгеләрне тапшыра:

1) кадрлар резервына кертү турында үтенеч белән гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

3) паспорт күчермәсе;

4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (булган очракта) һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

5) белем турында документ күчермәсе;

6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми;

7) Физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә керүгә каршы килә торган авыру булмау турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

10) дәгъвачының, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының муниципаль хезмәткә керү елыннан алдагы елга керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

10.1) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләр;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар;

Тиешле документларның төп нөсхәләре конкурс сайлавына килгәч дәгъвачының шәхсән үзе тарафыннан күрсәтелә.

Гариза кадрлар резервын формалаштыруга документларны теркәү журналында теркәлә. Гариза биргән гражданга, исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документлар алуда расписка бирелә.

Комиссия дәгъва кылучыдан аның шәхси мәгълүматларыннан файдалануга язма ризалык ала.

2.7. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8. Кадрлар резервына кертү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу Комиссия тарафыннан ике этапта уздырыла.

2.9. Беренче этапта тәкъдим ителгән документларны өйрәнү һәм дәгъвачының муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен законнарда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен ачыклау, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр өчен законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәү юлы белән кадрлар резервына дәгъвачыларның беренчел исемлеге төзелә.

Дәгъвачыларның беренчел исемлеге үз эченә кадрлар резервына кертүгә конкурс сайлавының кимендә ике дәгъвачысын ала.

2.10. Документлар кабул итү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң, Комиссия тапшырылган документлар нигезендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) дәгъва кылучыны конкурста сайлап алуның икенче этабына кертү турында;

2) дәгъвачыны конкурста сайлап алуның икенче этабына кертүдән дәлилләнгән баш тарту турында;

3) конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану турында.

2.11. Комиссия тарафыннан дәгъвачыны Конкурста сайлап алуның икенче этабында катнашуга кертмәү өчен нигез булып аның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен законнарда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килмәве, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр өчен законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәве тора.

2.12. Түбәндәге очракларда Комиссия тарафыннан конкурста сайлап алу булмаган дип таныла:

конкурс нигезендә сайлап алуга кимендә ике дәгъвачы гариза бирмәгәндә;

конкурс сайлавының беренче этабы нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән таләпләргә кимендә ике дәгъвачы туры килмәгәндә.

2.13. Комиссия дәгъвачыларга кабул ителгән карар турында конкурста сайлауның икенче этабын үткәрүгә кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итә.

2.14. Конкурста сайлап алуда катнашуга кертелмәгән дәгъвачы Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге карарга шикаять бирергә хокуклы.

2.15. Комиссия тарафыннан конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, беренче этаптан башлап, кабат конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү турында карар кабул ителә.

2.16. Икенче этапта конкурста сайлап алу процедурасы һәр дәгъвачының Комиссия утырышына мәҗбүри килү шарты белән уздырыла.

2.17. Конкурста сайлап алуның икенче этабында Комиссия беренчел исемлеккә кертелгән дәгъвачыларны, дәгъвачыларның законнарга каршы килмәгән һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийларын кулланып, конкурс процедуралары (тест, шәхси әңгәмә) нигезендә бәяли.

Бәяләү нәтиҗәләре буенча Комиссиянең һәр әгъзасы дәгъвачыга Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә торган конкурс бюллетененә кертелергә тиешле балл бирә. Дәгъвачыларны бәяләү 10 баллы система буенча башкарыла.

Дәгъвачыларны җыелган баллары буенча бәяләгәннән соң, Комиссия һәр дәгъвачының баллының нәтиҗәсен билгели.

2.18. Конкурс нигезендә сайлап алу тәмамлангач, Комиссия турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән Комиссия карары нигезендә, конкурста сайлап алуның икенче этабында иң күп балл җыйган ике дәгъвачы кадрлар резервына кертелә.

Конкурста сайлап алуның икенче этабы йомгаклары буенча иң күп балл җыйган дәгъвачы аны биләү өчен кадрлар резервы формалаштырылган вакантлы вазыйфага билгеләнгәндә, җирле үзидарә органы карары белән яисә тиешле вазыйфага билгеләнү турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле зат карары белән өстенлекле хокукка ия.

2.19. Конкурста сайлап алуда катнашкан барлык дәгъвачыларга конкурс

тәмамланган көннән соң 5 эш көне эчендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы тарафыннан язма рәвештә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре турында хәбәр ителә.

Конкурста сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Конкурс нигезендә сайлап алу тәмамланган көннән соң өч көн эчендә кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркемнәре Исемлегенә тиешле язма ясала.

Кадрлар резервы Исемлеге Комиссия раслаган көннән алып өч көн эчендә Арча муниципаль районы башлыгына, шулай ук вакантлы вазыйфаларны биләү өчен резерв төзелгән Арча муниципаль районы составына керүче җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә җибәрелә.

## III. Кадрлар резервын куллану

3.1. Биләү өчен кадрлар резервы формалашкан вакантлы вазыйфага җирле үзидарә органы яки тиешле вазыйфага билгеләү турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле вәкил карары белән конкурста сайлап алуның икенче этабы нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган гражданнар билгеләнә.

3.2. Җирле үзидарә органының яллаучысы яисә тиешле вазыйфага билгеләнү турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар Исемлеге составында бер үк сандагы балл җыйган гражданнар арасыннан берсен мөстәкыйль сайлап алалар.

Сайлау әңгәмә нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла, аның барышында вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданның әзерлек дәрәҗәсе (социаль адаптация, акыл дәрәҗәсе, психологик тотрыклылык, коммуникатив сыйфатлар) билгеләнә.

3.3. Кадрлар резервында торучы граждан кадрлар резервында формалашкан вакантлы вазыйфаны биләү тәкъдименнән баш тартканда, вакантлы вазыйфа азрак балл җыйган кадрлар резервындагы гражданга тәкъдим ителә.

3.4. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркеменә караган бер вазыйфаны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар тиешле җирле үзидарә органнары яисә вазыйфага билгеләү турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар карары буенча, аларның язмача ризалыгы белән, Арча муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркеменә караган башка вазыйфаларга, башкарма комитетлар җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш, билгеләп куела.

## IV. Кадрлар резервыннан төшереп калдыру

4.1. Кадрлар резервында торучы граждан аннан түбәндәге очракларда төшереп калдырыла:

– аны кадрлар резервы төзелгән вазыйфага билгеләгәндә;
– кадрлар резервында булу вакыты узганнан соң;
– язма гаризасына бәйле рәвештә;
– кадрлар резервы формалашкан муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган вазыйфаны яисә идарәче вазыйфаны биләү буенча тәкъдимнән кабат баш тартканда;
– дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләргә рөхсәтне рәсмиләштерү процедурасыннан баш тартканда, әгәр кадрлар резервы төзелгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматларга ия булуны таләп итә икән;
– гражданның үлеме (һәлак булуы) яисә хәбәрсез югалган дип танылуы, яисә аның закон көченә кергән суд карары буенча үлгән дип игълан ителүе;
– муниципаль хезмәткәр (граждан) кадрлар резервына кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасы кыскару;
– муниципаль учреждение үзгәртеп корылганда яисә бетерелгәндә;
– муниципаль хезмәт вазыйфасына карата квалификация таләпләре үзгәрү, әгәр мондый үзгәреш нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәр кадрлар резервында булган муниципаль хезмәт вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килмәсә;
– муниципаль хезмәткәргә карата “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясындагы 1 өлешендә каралган дисциплинар җәза куллану;
– Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешенең 5-11 пунктлары нигезендә муниципаль хезмәткәр булмаган граждан белән хезмәт шартнамәсен өзү;
– «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясында каралган очракларда муниципаль хезмәттән азат итү.

4.2. Кадрлар резервында торучы гражданны төшереп калдыру Комиссия карары нигезендә башкарыла.

Күрсәтелгән карар нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты кадрлар секторы тарафыннан кадрлар резервында торучы гражданнар исемлегенә тиешле язма ясый. Әгәр муниципаль хезмәткәр кадрлар резервыннан төшереп калдырылса, аның шәхси эшенә тиешле белешмәләр кертелә.

4.3. Кадрлар резервыннан төшереп калдырылган гражданнарга кабул ителгән карар турында язма рәвештә Комиссиянең тиешле карары кабул ителгән вакыттан соң биш көн эчендә хәбәр ителә.

## V. Күчеш нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмә үз көченә кергәнче формалашкан кадрлар резервына кертелгән гражданнар кадрлар резервына кертелгән гражданнар исемлегендә билгеләнгән срок узганчы кала.

Арча муниципаль районында
муниципаль хезмәт
вазыйфаларының югары һәм төп
төркеменә караган вакантлы
вазыйфаларны биләү өчен кадрлар
резервы турындагы Нигезләмәгә
1 нче кушымта

# АНКЕТА

Фото өчен урын

1. Фамилия ______________________

Исем ______________________

Ата исеме ______________________

| | |
|---|---|
| 2. Фамилия, исем яки ата исеме үзгәртелгә очракта, аларны, шулай ук кайсы сәбәп буенча үзгәрткәнне күрсәтегез | |
| 3. Туган ел, ай, көн, урын (авыл, шәһәр, район, өлкә, край, республика, ил) | |
| 4. Гражданлык (әгәр үзгәртсәгез, әгәр башка дәүләт гражданлыгына ия булсагыз, кайчан һәм нинди сәбәпләр аркасында үзгәрүен күрсәтегез) | |
| 5. Белем (кайчан һәм нинди уку йортлары тәмамладыгыз, диплом номерлары)<br>Әзерлек юнәлеше яки диплом буенча һөнәре<br>Диплом буенча квалификациясе | |
| 6. Югары уку йортыннан соң һөнәри белеме: аспирантура, адъюнктура, докторантура (белем бирү яки фәнни учреждениенең исеме, тәмамлау елы)<br>Гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем (бирелү вакыты, дипломнар, аттестатлар номерлары) | |
| 7. Нинди чит телләр һәм Россия Федерациясе халыкларының телләре һәм нинди дәрәҗәдә (сүзлек белән укыйсыз һәм тәрҗемә итәсез, укыйсыз һәм иркен аралаша аласыз) беләсез | |
| 8. Федераль граждан хезмәтенең класслы чиннары, дипломатик ранглар, хәрби яисә махсус исем, | |

| | |
|---|---|
| хокук саклау хезмәтенең класс чиннары, Россия Федерациясе субъекты граждан хезмәтенең класслы чиннары, дәүләт хезмәтенең квалификация разряды, муниципаль хезмәтнең квалификация разряды һәм класс чиннары (кем һәм кайчан бирелгән һәм кем тарафыннан) | |
| 9. Хокем ителдегезме, кайчан һәм ни очен (Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә тутырыла) | |
| 10. Эш, хезмәт, уку дәверендә дәүләт серен белү, аның формасы, номеры һәм датасы (әгәр булса) | |

11. Хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эш (югары һәм урта махсус уку йортларында уку, хәрби хезмәт, эшмәкәрлек эшчәнлеге һ.б.).

Әлеге пунктны тутырганда, оешманы үз вакытындагыча атамасын, хәрби хезмәтне хәрби хезмәт вазыйфасын һәм хәрби частьнең номерын күрсәтеп язарга кирәк.

| Ай һәм ел | | Оешманы күрсәткән вазыйфа | Оешманың адресы (шул исәптән чит илдә) |
|---|---|---|---|
| керү | китү | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

12. Дәүләт бүләкләре, башка аерымлык билгеләре

______________________________________________

______________________________________________

13. Туганнарыгыз (ата, ана, кыз һәм ир туганнар, балалар), шулай ук ир (хатын), шул исәптән аерылган, кыз һәм ир туганнарның ире ( хатыны), ирнең (хатынның) кыз туганнары һәм ир туганнары

Әгәр туганнары фамилиясен, исемен, этисенең исемен үзгәртсә, шулай ук аларның элекке фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтергә кирәк.

| Туганлык дәрәҗәсе | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | туган елы, ае, көне һәм туган урыны | Эш урыны (оешманың исеме һәм адресы), вазыйфасы | Өй адресы (теркәлү адресы, фактта яшәү адресы) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

14. Сезнең якын туганнарыгыз (әтиегез, әниегез, бертуган абый-энеләрегез, апа-сеңелләрегез һәм балаларыгыз), шулай ук хатын (ир), шул исәптән чит илдә даими яшәүче һәм (яисә) даими яшәү урынына башка дәүләткә китү өчен документлар рәсмиләштерүче хатын (ир), бертуганнар ____________________________

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, алар кайсы вакыттан бирле чит илдә яши)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

14(1). Ирнең (хатынның) гражданлыгы (подданство), әгәр хатынының (иренең) Россия Федерациясе гражданлыгы юк яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан тыш, шулай ук чит ил гражданлыгы булса, федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен Россия Федерациясе Чит эшләр министрлыгы системасында федераль дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә, аның буенча дипломатик ранг бирү каралган федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә күрсәтегез (тутырыла)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

15. Чит илдә булу (кайчан, кайда, нинди максат белән) ____________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

16. Хәрби бурычларга һәм хәрби исемгә мөнәсәбәт ________________________

______________________________________________________________________

17. Өй адресы (теркәлү, фактта яшәү адресы), телефон номеры (яисә элемтәнең башка төре)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

18. Паспорт яисә аны алмаштыручы документ

______________________________________________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

19. Чит ил паспорты булу ________________________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

20. Шәхси счетның иминият номеры (булганда)

_______________________________________________________________________________

21. ИНН ( булганда) ____________________________________________________________

22. Өстәмә белешмәләр (сайланулы вәкиллекле органнарда катнашу, үзегез турында хәбәр итәргә теләгән башка мәгълүмат) ___________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

23. Миңа анкетада ялган мәгълүматлар бирүем һәм квалификация таләпләренә туры килмәвем конкурста катнашудан һәм Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә яки Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен сәбәп булуы мәгълүм.

Миңа карата тикшерү чаралары үткәрү һәм минем шәхси мәгълүматларны эшкәртү (шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртү) белән килешәм.

"___" _________________ 20_____ ел

М.У.

Рәсмиләштерелүче затның фоторәсеме һәм хезмәт эшчәнлеге, хәрби хезмәте, белем алуы турында мәгълүматлар шәхесне раслаучы документларга, хезмәт кенәгәсендәге язмаларга, белем һәм хәрби хезмәт турында документларга туры килә.

"____" _______________20___ел ____________________________________________________

( кадрлар хезмәте хезмәткәре фамилиясе, имзасы)

Арча район Советының
02.02.2022 ел, № 47
карарына 2 нче кушымта

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркеменә керүче вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркеме исемлеге**

**1 нче бүлек. Вакантлы идарәчел вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркеме исемлеге**

| N. | Кадрлар резервы формалаштырылган идарә итү вазыйфасы | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Белеме (белгечлек күрсәтеп, нинди уку йорты һәм кайсы елда тәмамланды), гыйльми дәрәҗәсе | Эш урыны, биләгән вазыйфасы | Стажы | | | Кадрлар резервына кертү һәм хокукый акт реквизитлары | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | биләгән вазыйфа буенча эшләр | муниципаль хезмәт | белгечлек буенча эшләр | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Муниципаль учреждение исеме | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |

**2 нче бүлек. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар төркеме исемлеге**

| N. | Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасыннан тыш, кадрлар резервы төзелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары төркеменә караган вазыйфа | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Белеме (белгечлек күрсәтеп, нинди уку йорты һәм кайсы елда тәмамланды), гыйльми дәрәҗәсе | Эш урыны, биләгән вазыйфасы | Стажы | | | Кадрлар резервына кертү һәм хокукый акт реквизитлары | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | биләгән вазыйфа буенча эшләр | муниципаль хезмәт | белгечлек буенча эшләр | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Муниципаль район Советы аппараты | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| Муниципаль район Башкарма комитеты аппараты | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| Муниципаль районның шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |